**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**18нче июнь 2020нче ел** **№ 239**

**Татарстан Республкасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советының**
**дүртенче чакырылыш депутатларын**
**сайлауларын билгеләү турында**

2002нче елның 18нче июненнән 67 номерлы «Гражданнарның сайлау хокукларының һәм референдумда катнашуга хокукның төп гарантияләре турында» Федераль законының 10нчы статьясына, 2003нче елның 6нчы октябреннән 131 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең төп принциплары турында» Федераль законының 23нче статьясына, 2007нче елның 7нче маеннан 21 номерлы Татарстан Республикасының сайлау кодексының 105нче статьясының 1нче кисәгенә, Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Уставының 12нче статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советының дүртенче чакырылыш депутатларын сайлауларын 2020нче елның 13нче сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Новый Зай» һәм «Зәй офыклары» газеталарында кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сәвәләй авыл җирлеге
Советы рәисе С.К.Маклаков